**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 10 ноябрь № 858

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары туклануының көндезге рационы кыйммәтен һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен нормативларны билгеләү турында» 2016 ел, 26 октябрь, 786 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары туклануының көндезге рационы кыйммәтен һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен нормативларны билгеләү турында» 2016 ел, 26 октябрь, 786 нчы карарына (2017 ел, 25 гыйнвар, 22 нче һәм 2017 ел, 5 сентябрь, 633 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Белем бирү оешмаларына инвалид балалар, I һәм II төркем инвалидлар, бала чактан инвалид булган студентларга, Чернобыль АЭСында һәлакәт һәм башка радиация һәлакәтләре аркасында, Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган студентларга, хәрби хезмәт узган чорда алган хәрби имгәнү яки авыру аркасында инвалидлар һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары булган, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә, Россия

Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының эчке гаскәрләрендә һәм федераль дәүләт органнарында, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә, федераль башкарма хакимият органнары каршындагы инженер-техник, юл-төзелеш хәрби формированиеләрендә һәм гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итәргә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының коткару хәрби формированиеләрендә, Россия Федерациясенең Тышкы разведка хезмәтендә, федераль иминлек хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында һәм Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының мобилизация әзерлеген тәэмин итүче федераль органда солдатлар, матрослар, сержантлар, старшиналар биләргә тиешле хәрби вазыйфаларда контракт буенча кимендә өч ел хезмәт иткән һәм хәрби хезмәттән «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 ел, 28 март, ФЗ-53 нче Федераль законның 51 статьясындагы 1 нче пунктның «б» - «г» пунктчаларында, 2 нче пунктның «а» пунктчасында һәм 3 нче пунктның «а» - «в» пунктчаларында күздә тотылган нигезләр буенча азат ителгән гражданнар арасындагы студентларга, дәүләт социаль ярдәмен алучы студентларга билгеләнә торган социаль стипендияләр күләмнәрен билгеләгәндә бу карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тиешле нормативларга карата 1,5 арттыру коэффициентын куллануны тәкъдим итәргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\858.docx